

Мордовия матбугат Үзәгендә Мордовия Правительствосы Председателенен беренче урынбасары – министр экономики, торговли и предпринимательства РМ Владимир Николаевич Мазов катнашында брифинг узды. Коронавирус эпидемиясенә каршы корәш буенча чикләvләр чорында республика предприятиеләренен эшен оештыру мәсьәләләре каралды. Исегезгә тошерәбез, Россия Президенты В.В.Путин тарафыннан эшчеләрнен хезмәт хакын 30 апрельгә кадәр саклап калып, эшсез кон режимын озайту турында Карар кабул ителде. Шул ук вакытта тобәкләргә чикләv чаралары комплексы буенча, килеп туган эпидемиологик вәзгыятьтән чыгып, остәмә вәкаләтләр – дополнительные полномочия бирелде. Шулай итеп, 2020нче ел 3 апрель Республика Мордовия Правительствосы Карары белән, эшсез коннәр кагылмаган организацияләр исемлеге расланган - утвержден. Владимир Николаевич Мазов ассызыклаганча, әлеге исемлеккә тулаем региональ продуктка зур олеш кертvче предприятиеләр кергән.
«В своих обращениях Президент России Владимир Владимирович Путин и Глава Мордовии Владимир Дмитриевич Волков четко акцентировали внимание на том, что борьба с коронавирусом на текущий момент стоит на основном месте, главная задача – сохранение жизни и здоровья людей», - ди Владимир Николаевич. Ул билгеләп vткәнчә, республикада икътисаднын барлык топ тармаклары эшли. Бvгенге кондә Мордовиядә авыл хужалыгы, светотехника, кабель продукциясе, вагон тозv, тозелеш һ.б. олкәләрдәге 63 эре предприятие vз эшчәнлеген алып бара. Аларда барлык санитар-профилактик чаралар саклана дип әйтте.
- Большинство предприятий региона сегодня работает в кооперации с крупными холдингами, поставляя разнообразную продукцию для нужд страны. Более того, экономика Мордовии полностью направлена на внешние рынки. Регион имеет торговые связи с 67 странами мира. В Мордовии развиваются системообразующие и знаковые для экономики страны отрасли, очевидно, в таком сложном положении мы как никогда нужны стране, поэтому осознавая всю ответственность приступаем к работе, - ди В.Н.Мазов. - ...Мордовия Правительствосы Карары нигезендә, исемлектә кvрсәтелгән предприятие һәм оешма житәкчеләренә әлеге чорда эшкә жәлеп ителгән һәм оешманын топ функцияләрен аварияләрсез гамәлгә ашыру очен кирәкле хезмәткәрләр исемлеген билгеләргә һәм расларга; яна коронавирус инфекциясе таралуга юл куймауга юнәлтелгән санитар-профилактика чараларын катгый vтәгәндә эшчәнлекне оештырырга һәм хезмәткәрләрне яшәv урыннарыннан эшкә һәм кире ойләренә кайтаруны оештырырга; бер бинада хезмәткәрләрнен кvпләп булуын булдырмас очен эш графигын vзгәртv, шул исәптән оешманын эш режимын кертv юлы белән дә», - дип ишеттерде брифингта.

Владимир Николаевич ассызыклаганча, катлаулы хәлләргә карамастан - милли проектларны гамәлгә ашыру безнен остә. Тозелеш комплексы аерым исәптә. - Ил лидеры инициаторы булган идеяләрне тормышка ашыру буенча жаваплылыкны бездән беркем дә тошермәде. РМ Башлыгы Владимир Волков срокларга һәм нәтижәләргә карата катгый таләпләр куя, шуна кvрә илкvләм проектларны гамәлгә ашыру эше аерым игътибарны таләп итә һәм бер генә минутка да туктый алмый, - диде В.Н.Мазов.
Владимир Николаевич Мазов билгеләп vткәнчә, республиканын кече һәм урта бизнес вәкилләре, барлык кызыксындырган сораулар буенча «Минем бизнес» Үзәге базасында эшли торган «кайнар линия» телефонына морәҗәгать итә алалар: 24-77-77.
Шактый кvп оешмалар элеккечә эшләмәячәк. Нигездә, бу хезмәт кvрсәтv олкәсе предприятиеләре: рестораннар, кафе, барлар, бассейннар, спорт vзәкләре, шәхси сауна, фитнес-клублар, кvнел ачу йортлары, театрлар, китапханәләр, кинотеатрлар, шулай ук матурлык салоннары һәм чәчтарашханәләр.

Наилә НАСЫРОВА